**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 июлендәге 2600 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 29 маендагы 4994 номерлы «Торак сатып алуга дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 29 маендагы 4994 номерлы «Торак сатып алуга дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү” процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында Дәүләт торак сертификатларын эшләп чыгару һәм гамәлгә кертү кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 17 февралендәге 459 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 26 декабрендәге 4694 номерлы “Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарының штат расписаниеләре турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарына туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 29 маендагы 4994 номерлы «Торак сатып алуга дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 24 июлендәге 4197 номерлы, 2014 елның 22 августындагы 5082 номерлы, 2015 елның 18 сентябрендәге 3505 номерлы, 2016 елның 27 маендагы 2182 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 6557 номерлы, 2019 елның 30 маендагы 2007 номерлы, 2019 елның 9 октябрендәге 3646 номерлы, 2020 елның 23 июлендәге 1966 номерлы, 2021 елның 14 маендагы 1194 номерлы, 2022 елның

21 гыйнварындагы 188 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 4636 номерлы һәм 2023 елның 3 февралендәге 346 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Торак сатып алуга дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- Бүлек – район(-нар) администрациясенең яки Идарәнең муниципаль хезмәт күрсәтү эшен гамәлгә ашыра торган бүлекләре»;

1.2. 2.5.1 пунктның «б» пунктчасында:

1.2.1. икенче абзацка «[фатирлар карточкасы күчермәсе]» сүзләреннән соң «, яки яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматны үз эченә алган, миграция өлкәсендә контроль орган тарафыннан бирелгән белешмә)» сүзләрен өстәргә;

1.2.2. бишенче абзацта «инвалидларның федераль реестрында» сүзләрен «“Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа” дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**